РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10.11.2022** Кукмара ш. **№ 387**

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе карарының 1 пунктына, түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзацны өстәп, үзгәреш кертергә:

«Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр һәм спорт идарәсе карамагындагы Кукмара муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә спорт, физкультура-сәламәтләндерү һәм ял итү хезмәтләрен күрсәткән өчен түләүдән азат итү;».

2. Әлеге карар 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**